**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**
Полковая ул., 9, с. Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422701

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «МИЛЕК ҺӘМ ЖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
Полковая урамы, 9, Биектау поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422701

Тел.: +7 (84365) 3-28-54, e-mail: pizobiektau@mail.ru

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**11 ноябрь 2021 ел** **№1300-б**

**Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Типовой регламентлар турында» 2021 елның 9 июлендәге 04-51/4811 номерлы соратуын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы «Дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» карарын үтәү йөзеннән, гражданнарның һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча структур бүлекчәләр эшчәнлеген регламентлаштыруны һәм стандартлаштыруны камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы нигезендә

1. Кушымтада бирелгән Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. Үз көчен югалткан дип танырга: «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенең «Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 13-р номерлы боерыгы.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: //pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис С.М.Минһаҗев

Кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының 2021 елның 11 ноябрьдә №1300-б боерыгы белән расланды

**Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба - муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы җир кишәрлеге формалашмаган һәм аның турында белешмәләр Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында (алга таба – ЕГРН) булмаган яисә җир кишәрлегенең чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш булган очракларга кагыла.

Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү этабында җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә бирү мөмкинлеге, шулай ук җир кишәрлеге биреләчәк хокук төре (милек, аренда, түләүсез файдалану) билгеләнә.

Әгәр җир кишәрлеген милеккә түләүле нигездә сатулар үткәрмичә бирү, арендага сатулар үткәрмичә бирү, милеккә бушлай бирү, даими вакыты чикләнмәгән файдалануга яки түләүсез файдалануга бирү алдан килештерелсә, җир кишәрлеге турында ЕГРНга белешмәләр керткәннән соң җир кишәрлеген бирү процедурасын тәмамлау өчен, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә түбәндәге муниципаль хезмәтләрнең берсен алуга кабат гариза бирергә кирәк:

муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага, милеккә түләүле нигездә торглар үткәрмичә бирү;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү.

1.2. Хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче, гариза бирүче).

Мөрәҗәгать итүчеләр мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле затлары һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) тәкъдим итә ала.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү:

1.3.1. муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендларында.

2) муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультацияләр гамәлгә ашырыла:

1) телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә - шәхсән яисә телефон аша;

2) Республика порталының интерактив формасында;

3) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (алга таба -Палата):

телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазьдә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәтне күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика реестрындагы белешмәләр нигезендә мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы программа тәэминатының хокук иясе белән лицензия яисә башка килешү төзүне таләп итә, түләү алуны яисә мөрәҗәгать итүчене теркәүне, авторизацияләүне күздә тота, яисә аларга шәхси мәгълүматлар бирүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә телефон аша кергән мөрәҗәгать нигезендә мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Палатаның урнашкан урыны (Палатаның урнашкан урыны: Биектау ав., Полк ур., 9; эш графигы: дүш. сиш.: 8:00 дән 16:00 га кадәр; пәнж: 8.00 дән 12.00 гә кадәр; чәр., җом. кабул итү юк; шим., якш. – ял көннәре, төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр, белешмәләр телефоны: 8(84365) 3-28-54) турында; муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категориясе турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карау өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча рәсми сайтта урнаштыру урыны турында; Палата вазыйфаи затларының гамәлләренә яисә гамәл кылмавына карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелергә мөмкин.

Язма мөрәҗәгать буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы бүлекнең вазыйфаи затлары язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм әлеге Регламентның шушы пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне җентекләп аңлаталар һәм мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавапны юллыйлар. Җаваплар мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм Палата биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында һәм муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган муниципаль хезмәт турында, урнашу урыны, белешмә телефоннары, Палатаның эш вакыты турындагы, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп), муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылган.

Гамәлдәге редакциядә административ регламент тексты муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яки Татарстан Республикасы шәһәр округында булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенең) алар нигезендә белешмәләр кертелә торган документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (хата, ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата яки башка шундый хата);

БИАС (ЕСИА) – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының үзара мәгълүматитехнологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификациянең бердәм системасы.

Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның (гариза бирүче гражданнарның һәм башкарма хакимият органнарындагы һәм җирле үзидарә

органнарындагы вазыйфаи затларының) дәүләт мәгълүмат системасында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны рөхсәт белән файдалануын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

КФҮ - «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮнең АМС (АИС МФЦ) - Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать аңлашыла.

1.6. Мөрәҗәгать итүченең сату үткәрмичә генә җир кишәрлеге сатып алуга хокукын раслый торган нигезләрнең һәм документларның тулы исемлеге Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмәт исеме

Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү.

### 2.2. Җирле үзидарәнең турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органы исеме

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ.

### 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

а) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар;

б) җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар;

в) мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясында каралган нигез буенча мөрәҗәгать иткәндә һәм өченче зат аукционда катнашырга ниятләве турында мөрәҗәгатьләр кергән очракта, җир кишәрлеген алдан килештерүдән баш тарту турында карар белән территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар.

Кирәк булган очракта, мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау турында карар нигезендә җир кишәрлеге төзергә мөмкин һәм әлеге кишәрлекне торгларда алу инициативасы белән чыгарга мөмкин.

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе электрон имза турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Палатаның вазыйфаи затының (яки Палатаның)

көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ рәвешендә (1а номерлы, 1б номерлы кушымталар) мөрәҗәгать итүчегә Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча КФҮтә Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган кәгазь чыганакка чыгартып алынган электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә.

2.3.4. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы карар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына җир кишәрлеге турында белешмәләр кертү өчен нигез булып тора һәм басылганнан соң ике ел дәвамында гамәлдә була.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яисә басма чыганакта электрон документның нөсхәсе рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу вакыты дәвамында алырга хокуклы.

### 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты - 10 эш көне.

Җир кишәрлегенең территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарда булуы һәм карау актын әзерләү өчен җир кишәрлегенә чыгу кирәк булуы турында мәгълүмат булган очракта, мөрәҗәгать итүче белән килештереп, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.15 статьясындагы 12 пункты нигезендә җир кишәрлеген урнашуның башка схемасын раслау мөмкинлеге булган очракта, - муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты 22 эш көненнән артык түгел.

Әгәр җир кишәрлеге төзергә кирәк булган җир кишәрлегенең урнашу схемасы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.5 статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булса, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза кергән көннән 45 көннән дә артмаган вакытка озайтыла. Башкарма комитет җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гаризаны карау вакытын озайту турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүче Регламентның 1.6.6. пунктында күрсәтелгән нигез буенча мөрәҗәгать иткән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясында билгеләнгән тәртиптә алда көтелгән җир кишәрлеге бирү турында хәбәр бастырып чыгару һәм аукционда катнашырга ниятләгән затлардан гаризалар җыю чорына озайтыла, ул 32 көннән дә артмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгән көннән соң икенче көннән исәпләнә башлый.

2.4.2. Башкарма комитетка әлеге гаризага беркетеп бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасында каралган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза кергән датага Башкарма комитет каравында башка зат

тарафыннан элек тапшырылган җир кишәрлегенең урнашу схемасы һәм бу схемаларда каралган җир кишәрлекләренең урнашу схемасы өлешчә яки тулысынча туры килсә, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору 64 эш көненнән дә артмаган вакытка гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хәбәрнамәне җибәргән көннән соң килүче көннән исәпләнә.

2.4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хәбәрнамәне (2 нче кушымта) җибәрү гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, хәбәрнамәне рәсмиләштергән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ формасындагы документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәтне, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать категориясенә һәм нигезләренә бәйсез рәвештә гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ;

2) мөрәҗәгать итүче вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш).

3) гариза:

- кәгазь чыганактагы документ формасында (3 нче кушымта);

- Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, Регламентның 2.5.5 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (тиешле белешмәләрне гаризаның электрон формасына кертү юлы белән тутырыла);

2.5.2. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гаризага кушымта итеп түбәндәгеләр бирелә:

1) мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итүче категориясе һәм 7 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә мөрәҗәгать нигезе буенча сатулар үткәрмичә җир кишәрлеге алу хокукын раслый торган документлар, Башкарма комитет тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына торган документлардан тыш;

2) соралган җир кишәрлеген барлыкка китерергә кирәк булган һәм аның чикләрендә мондый җир кишәрлеге барлыкка китерергә кирәк булган территорияне ызанлау проекты булмаган очракта, территория чикләренең характерлы нокталары координаталарын күрсәтеп, җир кишәрлегенең урнашу схемасы. Җир кишәрлегенең урнашу схемасы xml форматындагы яки башка форматтагы электрон документ рәвешендә яки «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләүгә һәм территориянең кадастр

планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә, басма чыганактагы документ рәвешендә әзерләнә торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы формасын әзерләгәндә,территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы форматына таләпләрне раслау турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән каралган башка форматларда тапшырыла;

3) линияле объектны урнаштыру максатларында төзелә торган урман кишәрлегеннән тыш, урман кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза бирелгән очракта, урман кишәрлекләренең проект документлары;

4) мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очракта, чит дәүләт законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе;

5) мондый ширкәткә җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яки мондый ширкәткә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәт тарафыннан әзерләнгән әлеге ширкәт әгъзаларының реестры.

5) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документлар.

2.5.3. Гариза үз эченә алырга тиеш:

1) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме, яшәү урыны, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслый торган документ реквизитлары (граждан өчен);

2) мөрәҗәгать итүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәве турындагы язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш;

3) әгәр мондый җир кишәрлегенең чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төгәллләштерелергә тиеш булса, аны бирүне алдан килештерү турында гариза кергән җир кишәрлегенең кадастр номеры (алга таба - сорала торган җир кишәрлеге);

4) сорала торган җир кишәрлеген барлыкка китерү күрсәтелгән проектта каралса, территорияне ызанлау проектын раслау турында карар реквизитлары;

5) әлеге җир кишәрлекләре турында белешмәләр Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән булса, территорияне ызанлау проекты, җир кишәрлегенең урнашу схемасы яки урман кишәрлекләренең проект документлары нигезендә алардан соралган җир кишәрлеген барлыкка китерү каралган җир кишәрлегенең кадастр номеры яки җир кишәрлекләренең кадастр номерлары;

6) җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә бирү нигезләре Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктында, 39.5 статьясында, 39.6 статьясындагы 2 пунктында яки 39.10 статьясындагы 2 пунктында каралган нигезләр арасыннан;

7) җир кишәрлеген бирү хокукның берничә төрендә мөмкин булса, мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген сатып алырга тели торган хокук төре;

8) җир кишәрлегеннән файдалану максаты;

9) әгәр җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелә икән, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген тартып алу турында карар реквизитлары;

10) җир кишәрлеге күрсәтелгән документ һәм (яки) проект белән каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән очракта, территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары;

11) мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу.

2.5.4. Гариза һәм аңа беркетеп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) Регламентның 2.5.5 пункты таләпләре нигезендә имза куелган (расланган) электрон документлар рәвешендә һәм басма чыганакта КФҮ аша;

2) Республика порталы аша электрон формада.

2.5.5. Физик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә БИАСта (ЕСИАда) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алуны стандарттан түбән булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре Республика порталы ярдәмендә гариза һәм кирәкле документлар җибәргәндә, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Соратуны Республика порталы аша тапшырганда, мөрәҗәгать итүче документларның электрон үрнәкләрен яисә әлеге пункт таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган документларны электрон формада тапшыра.

Регламентның 2.5.1 пунктының 2 пунктчасында, 2.5.2 пунктының 1, 3 – 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар әлеге документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның, шул исәптән нотариусларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныклана.

2.5.6. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлләрне башкару каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирү, гамәлләр башкару;

2) гамәлләр, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган килештерүләрне башкару, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган хезмәт күрсәтүләрдән, документлар һәм мәгълүмат алудан тыш (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр);

3) түбәндәге очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тарткан вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге турында хәбәр ителмәгән документлар яисә мәгълүмат бирүне:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләрен үзгәрүе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тартканнан соң бирелгән һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тартканнан соң мәгълүматның үзгәрүе;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тарткан очракта, Палатаның вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең хаталы яки хокукка каршы гамәлләре (гамәл кылмавы) фактын (билгеләрен) ачыклау, бу хакта муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тарткан очракта Палата җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр;

4) кәгазь чыганактагы электрон үрнәкләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь чыганакта тапшыру, мондый документларга тамгалар кую яисә аларны алу дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

1) юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта Федераль салым хезмәтеннән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратыла;

2) индивидуаль эшкуар мөрәҗәгать иткән очракта, Федераль салым хезмәтеннән Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратыла.

3) мөрәҗәгать итүче кече һәм урта эшкуарлык субъекты булган очракта, Федераль салым хезмәтеннән кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрыннан өземтә соратып алына;

4) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән хокук иясен билгеләү өчен җир кишәрлегенә ЕГРНнан өземтә;

5) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез милек объектына ЕГРНнан өземтә (яисә объектларның булмавы турында хәбәрнамә);

6) дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән аерым затның җир кишәрлекләренә элек булган (бар) хокуклары турында ЕГРНнан өземтә;

7) «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.5 статьясында каралган очракта, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы җир кишәрлеген урнаштыру схемасын килештерү;

8) инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды;

9) адрес бирелә торган объектка бирелгән адрес турында белешмәләр - федераль мәгълүмати адреслар системасы;

10) урман кишәрлекләре чикләре турында белешмәләр - Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы;

11) су объектлары чикләре турында белешмәләр – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы;

12) сорала торган җир кишәрлегендәге төзелешләр булу турында белешмәләр - электрон хуҗалык кенәгәсе;

13) җир кишәрлеге бирү өчен чикләүләр булу яисә булмау турында (шул исәптән территориаль зона, кызыл линияләрнең чикләре, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары турында) бәяләмә - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге;

14) җир кишәрлеген беренче чиратта яки чираттан тыш алу хокукын гамәлгә ашыручы затлар реестрыннан белешмәләр – Башкарма комитет;

15) мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе Граждан хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яки Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) - Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестры яисә Социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы;

16) ышаныч кәгазен бирү һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр - нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче категориясенә һәм мөрәҗәгатьнең нигезенә бәйле рәвештә соратып алына торган өстәмә документлар исемлеге регламентка 7 нче кушымтада китерелгән.

2.6.3. Кирәк булган очракта, җир кишәрлегенә чыгып карау гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре буенча тикшерү акты төзелә (фотога төшереп теркәү белән җир кишәрлеген карау).

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче, гаризаларны Республика порталы аша яисә КФҮкә кәгазь чыганакта тапшырганда, Регламентның 2.6.1 пунктындагы 1 – 6

пунктчаларында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында бирергә хокуклы.

2.6.5. Күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, Башкарма комитеты структур бүлекчәләре тарафыннан документларны һәм белешмәләрне тапшырмау (вакытында тапшырмау) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.6. Күрсәтелгән органнарның соратылган һәм алар карамагында булган документларны яисә белешмәләрне тапшырмаган (вакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яисә) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яисә башка җаваплылыкка тартылырга тиеш.

2.6.7. Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагындагы документларны, белешмәләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү кертелүне раслый торган белешмәләрне таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагындагы белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

### 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге (документларны асылы буенча карамыйча кире кайтару)

2.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

Регламентның 2.5.1 – 2.5.4 пунктлары нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиеш булган документларны тапшырмау яисә каршылыклы белешмәләр булган документлар тапшыру;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турында белешмәләр расланмау, гариза (сорату) мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итәргә вәкаләте булмаган зат тарафыннан бирелү;

документларны тиешле органга тапшырмау;

дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы белешмәләр, алдан сөйләшенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бер төрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар булган документлар, үз көчен югалткан документлар тапшыру;

Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

гаризаның электрон формасында мәҗбүри юлларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу;

электрон формадагы гаризага (соратуга) һәм башка документларга электрон имза гамәлдәге законнарны бозып куелган;

электрон документлар аларны бирү форматларына туры килми һәм (яки) укылмый;

җир кишәрлегенә салынган тәэмин итү чаралары һәм (яки) күрсәтелгән күчемсез мөлкәтнең объектларына файдалану хокуклары булу;

Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлегендә урнашкан капиталь төзелеш объектына хокукы булмау;

капиталь төзелеш объекты өлешле милектә булган очракта, җир кишәрлеген алу өчен гариза бер милекчедән генә бирелү;

элек Татарстан Республикасы территориясендә беренче чиратта яисә чираттан тыш җир кишәрлеге бирелгән җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш алу хокукына ия булган затның җир кишәрлеге бирүне сорап мөрәҗәгать итүе;

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган дәүләт мөлкәте исемлегенә яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир кишәрлеген бирү турында гариза белән кече яки урта эшмәкәрлек субъекты булмаган зат яки әлеге Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган зат мөрәҗәгать итү.

2.7.2. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар мөрәҗәгать итүчене кабул итү вакытында да, гаризаны теркәгән көннән алып 7 эш көненнән артмаган вакыт эчендә Палатаның җаваплы вазыйфаи заты, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) алганнан соң да кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, регламентка 5 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Палатаның вәкаләтле вазыйфаи заты (Палата) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Республика порталында шәхси кабинетына һәм (яки) КФҮкә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.7.5. Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар Бердәм порталда бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү вакытлары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып, Палатага барлыкка килүе әлеге гаризага беркетеп бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасында каралган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза кергән көнгә, Палата тикшерүендә булган элек башка зат тарафынан

тапшырылган җир кишәрлегенең урнашу схемасы һәм әлеге схемаларда каралган җир кишәрлекләренең урнашу урыны өлешчә яки тулысынча туры килү тора.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар, сәбәпләрен һәм туктатып тору срогын күрсәтеп, Регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Палатаның вәкаләтле вазыйфаи заты (Палата) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул ителгән көнне мөрәҗәгать итүчегә Республика порталының шәхси кабинетына һәм (яки) КФҮкә җибәрелә.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

2.8.3.1. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гаризага беркетеп бирелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясындагы 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча раслана алмый, атап әйткәндә:

1) җир кишәрлегенең урнашу схемасының аның формасына, форматына яисә 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән аны әзерләүгә карата таләпләргә туры килмәве;

2) аның урнашу схемасы белән каралган җир кишәрлегенең урнашу урынының гамәлдә булу срогы бетмәгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында элегрәк кабул ителгән карар нигезендә барлыкка килә торган җир кишәрлегенең урнашу урыны белән тулысынча яки өлешчә туры килүе;

3) җир кишәрлеген урнаштыру схемасын Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясында каралган барлыкка килә торган җир кишәрлекләренә карата таләпләрне бозып эшләү, атап әйткәндә:

а) аларга карата шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) размерлары әлеге регламентлар белән билгеләнә;

б) шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый яисә аларга карата шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) размерлары Россия Федерациясе Җир кодексы, башка федераль законнар нигезендә билгеләнә;

в) җир кишәрлекләре чикләре муниципаль берәмлекләр чикләрен һәм (яки) торак пунктлар чикләрен кисәргә тиеш түгел;

г) мондый җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез милек объектларыннан файдалану мөмкинлеге булмауга китерә торган җир кишәрлекләре барлыкка китерү рөхсәт ителми;

д) барлыкка килә торган җир кишәрлекләренә карата сакланган йөкләмәләр (чикләүләр) рөхсәт ителгән файдалану нигезендә әлеге җир кишәрлекләреннән файдаланырга мөмкинлек бирмәсә, җир кишәрлекләрен бүлү, яңадан бүлү яки бүлеп бирү рөхсәт ителми;

е) җир кишәрлекләрен барлыкка китерү чикләргә керүгә, чикләрне кысуга, чикләрнең бозылуына, полосалар барлыкка килүгә, күчемсез милек объектларын урнаштыру мөмкин булмауга һәм җирләрдән рациональ файдалануга һәм саклауга комачаулаучы башка җитешсезлекләргә китерергә, шулай ук Россия Федерациясе

Җир кодексы, башка федераль законнар белән билгеләнгән таләпләрне бозарга тиеш түгел;

ж) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен, файдалы казылма чыга торган урыннарны эшләү өчен, линия объектларын, гидротехник корылмаларны, шулай ук сусаклагычларны, башка ясалма су объектларын урнаштыру өчен барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән тыш, территориаль зоналар, урманчылыклар, урман парклары чикләрен кисә торган җир кишәрлеге барлыкка китерү рөхсәт ителми;

4) җир кишәрлегенең урнашу схемасының расланган территорияне планлаштыру проектына, җир төзелеше документларына, аеруча саклана торган табигать территориясе турында нигезләмәгә туры килмәве;

5) җир кишәрлеген урнаштыру схемасы белән каралган җир кишәрлегенең территорияне ызанлау проекты расланган территория чикләрендә урнашу.

2.8.3.2. Барлыкка килергә тиешле җир кишәрлеге мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясындагы 1 - 13, 14.1 - 19, 22 һәм 23 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый, атап әйткәндә:

1) җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә генә алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать итү;

2) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш, җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу яки аренда хокукында бирелгән;

3) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, әлеге ширкәт әгъзасының мондый гариза белән (әгәр мондый җир кишәрлеге бакча яки яшелчә бакчасы булса) яисә гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләре мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булса);

4) җир кишәрлеген урнаштыру турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге бинаның, корылмаларның, андагы биналарның, тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе мөрәҗәгать иткән, шулай ук җир кишәрлеге бирү турында гариза тапшырылган һәм анда урнашкан биналарга, корылмаларга, төзелеше тәмамланмаган объектка карата рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар яки рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яисә аны күрсәтелгән карарлар белән билгеләнгән таләпләргә һәм вакытларга туры китерү турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, гражданнар яисә юридик затлар карамагындагы бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 11 өлешендә

каралган бурычлар үтәлмәгән;

5) җир кишәрлегендә сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге бинаның, корылмаларның, андагы биналарның, тәмамланмаган төзелеш объектының хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан;

6) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән хокукта бирү рөхсәт ителми;

6.1) Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пункты нигезендә әйләнештән алынган җир кишәрлекләренә Федераль милектә булган түбәндәге объектлар биләгән җир кишәрлекләре керә:

а) дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар (Россия Федерациясе Җир кодексының 95 статьясында каралган очраклардан тыш);

б) Россия Федерациясе Кораллы Көчләре, башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм органнар даими эшчәнлек өчен урнаштырылган биналар, корылмалар (федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш);

в) хәрби судлар урнашкан биналар, корылмалар;

г) Федераль куркынычсызлык хезмәте оешмалары объектлары;

д) дәүләт саклау органнары оешмалары объектлары;

е) атом энергиясен куллану объектлары, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктлары;

ж) эшчәнлек төрләре нигезендә ябык административ-территориаль берәмлекләр төзелгән объектлар;

з) Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте учреждениеләре һәм органнары объектлары;

и) хәрбиләр һәм гражданнар күмелгән урыннар;

к) Россия Федерациясе дәүләт чиген саклау мәнфәгатьләрендә төзелгән инженер-техник корылмалар, элемтә линияләре һәм коммуникацияләр;

6.2. Әйләнеше чикләнгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 5 пункты нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган түбәндәге җир кишәрлекләре керә:

а) Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән аеруча саклана торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан җирләр;

б) урман фонды җирләре составында булган җирләр;

в) алар чикләрендә су объектлары урнашкан дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләр;

г) аеруча әһәмиятле Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары, Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән тарихи-мәдәни тыюлыклар, археологик мирас объектлары, музей-тыюлыклар урнашкан җирләр;

д) оборона һәм иминлек, оборона сәнәгатен, таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4

пунктында күрсәтелмәгән җирләр;

е) ябык административ-территориаль берәмлекләр чикләрендә Россия Федерациясе Җир кодексының 27 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелмәгән җирләр;

ж) диңгез транспорты, эчке су транспорты, һава транспорты объектларын, һава хәрәкәтен һәм судно йөрешен навигация белән тәэмин итү корылмаларын, гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын, шулай ук федераль әһәмияттәге, региональ әһәмияттәге, муниципальара әһәмияттәге яисә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) файдалану (алга таба - урнаштыру) өчен билгеләнгән җирләр;

з) космик инфраструктура объектлары урнашкан җирләр;

и) гидротехник корылмалар объектлары астындагы җирләр;

к) агулы матдәләр, наркотик чаралар җитештерү өчен бирелгән җирләр;

л) куркыныч калдыклар, радиоактив матдәләр белән пычранган, биоген пычратуга дучар ителгән, деградациягә дучар ителгән башка җирләр;

м) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җирләр чикләрендә урнашкан җирләр;

н) эчә торган су белән һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналарының беренче һәм икенче поясларында;

7) резервлау максатлары өчен җир кишәрлеге бирү очракларыннан тыш, мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген милеккә бирү, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү яки җир кишәрлеген арендага бирү, җир кишәрлеген резервлау турында карарның гамәлдә булу вакытыннан артып киткән вакытка түләүсез файдалануга бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган булу;

8) җир кишәрлеге бирү турында гариза белән шул җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылмалар, төзелеше тәмамланмаган объект милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенә ия булучы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аңа карата төзелеш территориясен үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан;

9) мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектлар төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан яисә җир кишәрлеге аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән;

10) җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән әлеге затның әлеге объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тоткан территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән һәм территорияне

планлаштыру буенча расланган документ нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән;

11) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә аны уздыру турында хәбәр урнаштырылган аукцион предметы булып тора;

12) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 маддәсенең 4 пунктындагы 6 пунктчасында каралган аукцион яисә мондый җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 4 пункты нигезендә төзелгән һәм вәкаләтле орган тарафыннан әлеге аукционны Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләрдә үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән очракта, аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру турында гариза кергән;

13) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан һәм урнаштырылган;

14) сорала торган җир кишәрлеге тулысынча җир кишәрлекләреннән файдалануның билгеләнгән чикләүләре җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлегеннән файдалану максатлары нигезендә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирми торган, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан;

15) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, җир кишәрлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм иминлек ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир кишәрлекләре исемлегенә кертелмәгән;

16) бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтенә җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән чик күләмнән артып киткән;

17) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

18) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылма урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать иткән;

19) җир кишәрлеген гаризада соралган хокук төрендә бирү рөхсәт ителми;

20) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны бирүне алдан килештерү турында аның гамәлдә булу вакыты чыкмаган карар кабул ителгән һәм җир кишәрлеге бирү турында гариза белән бу карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;

21) мондый җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш, җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү максаты мондый җир кишәрлеген тартып алу максатларына туры килми;

2.8.3.3. Чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиешле җир кишәрлеге мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясындагы 1-23 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирелә алмый, атап әйткәндә:

1) Регламентның 2.8.3.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча;

2) территорияне планлаштыру проекты белән расланган линияле объект урнаштыру очракларыннан тыш, җир кишәрлегеннән файдалануның рөхсәт ителгән төре җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлегеннән файдалану максатларына туры килми;

3) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата файдалануның рөхсәт ителгән төре билгеләнмәгән;

4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер категориягә кертелмәгән.

2.8.3.4. Гражданнарга торак пункт, бакчачылык чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыклары эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыкканнан соң утыз көн эчендә башка гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан аукционда катнашу нияте турында гаризалар керү.

2.8.3.5. Мөрәҗәгать итүчегә бер үк вакытта милек хокукында һәм (яки) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен башка хокукта булган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июленнән 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән максималь күләмнән артып китү.

2.8.3.6. Җир кишәрлегенең коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте чикләрендә булуы һәм территорияне оештыру һәм төзү проекты яисә әлеге берләшмә территориясен ызанлау проекты булмау.

2.8.3.7. Җир кишәрлеген сорау максаты шәһәр төзелеше регламентында шәһәр төзелешен зоналаштыру документларында тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән файдалануның рөхсәт ителгән төп төренә туры килми.

2.8.3.8. Сорала торган җир кишәрлеген файдалану максаты территориаль зоналарда билгеләнгән территорияләрне планлаштыру проекты, территорияне

ызанлау проекты территориаль зоналарында билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләренә туры килмәве (шул исәптән территориаль зоналарда җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә билгеләнгән файдалануның рөхсәт ителгән төрләрендә төрлечә укылганда).

2.8.3.9. Сорала торган шәхси торак төзелеше өчен рөхсәт ителгән җир төре белән җир кишәрлегендә торак булмаган бина урнашкан.

2.8.3.10. Коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәте чикләреннән читтә урнашкан сорала торган җир кишәрлеге төзелешенең (шәхси торак йорт, торак дача йорты, бакча йорты) гомуми мәйданы төзелешнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларыннан артып китә.

2.8.3.11. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләре алу өчен чит ил гражданы, чит ил юридик заты, гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук устав (туплау) капиталында чит ил гражданнары, чит ил юридик затлары, гражданлыгы булмаган затлар өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат мөрәҗәгать итү.

2.8.3.12. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлеген урнаштыру схемасын килештерүдән баш тартуы турында хәбәрнамәсе.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 1б номерлы кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты (Башкарма комитет) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Республика порталында шәхси кабинетына һәм (яки) КФҮкә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә

2.8.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү вакытлары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүмат

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәттән файдалану турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

2.12.1. Муниципаль хезмәт алуга гариза биргәндә көтү вакыты - 15 минуттан да артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәттән файдалану турында соратуны, шул исәптән электрон формада, теркәү вакыты һәм тәртибе

2.13.1. КФҮкә шәхси мөрәҗәгать иткәндә гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүчегә КФҮнең АМСнан (АИС МФЦ) гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы белән раслау кәгазе (расписка) бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүче Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның теркәлү номеры һәм бирү датасы күрсәтелгән гаризаның җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәләр тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясендә тотрыклы тайпылышлары булган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм итү;

2) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

3) чикләнгән тормыш эшчәнлеген исәпкә алып, инвалидларның хезмәт күрсәтүгә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидларга кирәкле тавышлы һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифты белән башкарылган билгеләр ярдәмендә кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче кертүгә рөхсәт;

6) эт-озатучыны махсус укытуны раслый торган һәм «Эт-озатучыны махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән формада һәм тәртиптә бирелгән документ булганда, эт-озатучыны кертүгә рөхсәт;

2.14.3. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм Регламентның 2.14.2. пунктындагы 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

## 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашу саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, мөрәҗәгать итүченең сайлап алу буенча (экстерриториаль принцип) җирле үзидарә башкарма комитеты органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә 210 –ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында турында сорату җибәрү юлы белән (комплекслы сорату) муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге булу яисә булмау (шул исәптән тулы күләмдә)

2.15.1. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән бер дәрәҗәдә файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

3) Палата хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә КФҮ хезмәткәрләре белән аралашуы гаризаны һәм барлык кирәкле документларны биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

4.2) КФҮтә электрон документның басма чыганакта нөсхәсе формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу кирәк булган очракта бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлары белән бер аралашу дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә Бердәм порталны, Республика порталын, терминал җайланмаларын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта, КФҮдә алырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына яисә экстерриториаль принцип буенча фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә сайлау буенча теләсә кайсы КФҮтә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче муниципаль хезмәтне комплекслы сорату составында алырга хокуклы.

## 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелсә) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон формада күрсәтелгәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документлар, шул исәптән Республика порталын кулланып, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә электрон үрнәкләре расланган документларны һәм мәгълүматны бирергә;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

г) Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Палатаның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә шикаять бирергә;

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә бирү зарурлыгыннан башка, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең кабул итүгә язылуы (алга таба - язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигында билгеләнгән чикләрдә кабул итү өчен буш булган теләсә нинди датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеләнгән датага язылу бу дата башланганчы бер тәүлек кала тәмамлана.

Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә соратып алына торган мәгълүматларны, шул исәптән түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

үзе теләгән дата һәм кабул итү вакыты.

Алдан язылу вакытында мөрәҗәгать итүче хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче биргән документларга туры килмәве очрагында, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә раслау талоны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда мөрәҗәгать итүчегә кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан соң 15 минут үткәннән соң килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация үтүдән тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр кылуны, кабул итү максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен вакыт интервалының озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре. Бүлектә гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен, шул исәптән алар алырга дип мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары булырга тиеш

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар җибәрү;

4) документларны һәм (яки) кергән мәгълүматларны эшкәртү, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар комплектын формалаштыру;

5) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Административ процедура үтәүне башлау өчен мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате нигез була.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

- күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә - КФҮ хезмәткәре;

- мөрәҗәгать итүче Палатага мөрәҗәгать иткәндә – Палата рәисенең урынбасары (алга таба-консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында консультация алу өчен КФҮкә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә бирелә торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны ирекле файдаланудагы КФҮ сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru) ала ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча бирелгән консультацияләр.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Палатага телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Орган сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары буенча, шул исәптән документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә мәгълүмат бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча бирелгән консультацияләр.

### 3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау

3.3.1. КФҮ яки КФҮнең читтәге эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) шәхсән КФҮгә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре:

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү үткәрә;

КФҮнең АМСнда гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кәгазь чыганакта тапшырганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮнең АМСнан гаризаны бастырып чыгара;

тикшерү һәм имза кую өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имза куелганнан соң имзаланган гаризаны КФҮнең АМСта сканерлый;

электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон үрнәкләрен КФҮнең АМСна урнаштыра, электрон эш формалаштыра;

имза куелган гаризаны һәм басма чыганактагы документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүне раслау кәгазе (расписка) бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: җибәрүгә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. Мөрәҗәгать итүче КФҮнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән бер эш көне эчендә КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документларны (электрон эшләр пакетлары составында) электрон формада Палатага җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен электрон формада документлар кабул итү.

3.3.2.1. Мөрәҗәгать итүче электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизацияне үти;

Республика порталында электрон гариза формасын ача;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки документларның электрон үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм ризалык бирү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (тиешле электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

3.3.2.2. Процедураларның нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Башкарма комитетка җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Башкарма комитет тарафыннан документлар комплектын карау

3.3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар керү административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазифаи зат (хезмәткәр) булып Палата рәисенең урынбасары тора (алга таба - документлар кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат).

Документларны кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат карауга документлар кергәч:

гаризага эш номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, бу Республика порталының шәхси кабинетында чагыла;

кергән электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада бирелгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

электрон документларның тулылыгын, укылышын тикшерә;

Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән электрон имзаның дөреслеге шартлары үтәлешен тикшерә (мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктының 1-11 пунктчаларында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның дөреслеге шартларын үтәмәү ачыкланган очракта, баш тарту турындагы карар проекты 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы әлеге карарны кабул итүгә нигез булып торган пунктларны үз эченә алырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә исеме күрсәтелмәгән, дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләре булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) турында мәгълүмат булырга тиеш), Регламентка 5 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.6.4. пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктының 1-11 пунктчаларында каралган нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазифаи зат, гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза керү турында гаризаның теркәү номеры, гаризаны алу датасы, аңа беркетелгән документ файлларының исемнәре исемлеге, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәрә.

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.3.3.3. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза карауга кергән көннән бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: карауга кабул ителгән гариза яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара

соратулар җибәрү

3.4.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән) мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документларны алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Палата рәисенең урынбасары (алга таба - ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Регламентның 2.6. пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне тапшыру турында соратуларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон формада төзи һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны карауга кабул иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнары карамагындагы оешмаларга җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүчеләр белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мөрәҗәгатьләр нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәге срокларда үтәлә:

Росреестр белгечләре җибәргән документлар (белешмәләр) буенча - өч эш көненнән дә артмый;

җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы оешмалар карамагында булган документлар (белешмәләр) буенча – өч эш көненнән дә артмый;

калган тәэмин итүчеләр буенча – документ һәм мәгълүмат бирүче органга яки оешмага ведомствоара соратулар килгән көннән биш көн эчендә, әгәр ведомствоара мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Ведомствоара мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

ведомствоара электрон бәйләнешләр системасы аша соратып алына торган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне), яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда, баш тарту турында хәбәрнамәне ала;

Регламентның 2.7.1 пунктының 12-16 пунктчаларында каралган нигезләр булганда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр дөрес булмаган һәм (яки)

каршылыклы белешмәләр булган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документлар (мәгълүмат, белешмәләр) исеме турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш), Регламентка 5 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерү Регламентның 3.6.4. пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.4.3. Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән Регламентның 2.13 пункты нигезендә гаризаны теркәгән мизгелдән алып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.4. Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яисә ведомствоара мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән документлар һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы өч эш көне тәшкил итә.

### 3.5. Документларны һәм (яки) кергән мәгълүматларны эшкәртү, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар комплектын формалаштыру

3.5.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып, ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан ведомствоара соратуга җавап керү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Палата рәисенең урынбасары тора (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү ӧчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.5.2. Документлар (мәгълүмат) эшкәртү өчен җаваплы вазифаи зат:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир кишәрлеген урнаштыру схемасы кәгазь чыганакта тапшырылган очракта, күрсәтелгән схеманы электрон документ формасында әзерләүне тәэмин итә;

Регламентның 2.8.1. пунктында билгеләнгән нигезләр булган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул ителә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору сәбәпләрен һәм вакытларын күрсәтеп, туктатып тору турында карар Регламентка 2 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, Палатаның вәкаләтле вазыйфаи заты (Палата) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул ителгән көнне Республика порталының шәхси кабинетына һәм КФҮ кә җибәрелә;

җир кишәрлеген урнаштыру схемасын карау барышында башка схеманы раслау мөмкинлеге ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүчегә территориянең кадастр

планында җир кишәрлеген урнаштыруның башка схемасын килештерү мөмкинлеге турында хәбәрнамәне (4 нче кушымта) Республика порталының шәхси кабинетына һәм җир кишәрлеген урнаштыруның башка схемасын килештерү турында хәбәрнамәне КФҮкә җибәрә;

җир кишәрлеген карау һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне бәяләү өчен урынга чыгу кирәклеге турында карар кабул итә;

урынга чыгу кирәк булган очракта, җир кишәрлегенә чыгу датасын килештерү турында хәбәрнамәне мөрәҗәгать итүчегә Республика порталының шәхси кабинетына һәм КФҮкә җибәрә;

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар комплекты, җир кишәрлегенә чыгу датасын килештерү турында хәбәрнамә.

3.5.3. Техник мөмкинлек булган очракта, Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь вакыты бер эш көне тәшкил итә.

3.6. Муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү

3.6.1. Административ процедураны үти башлау өчен нигез булып административ процедураны үтәүгә вәкаләтле вазыйфаи затның документларны (мәгълүматны) эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи заттан документлар комплектын алу тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Палата рәисенең урынбасары (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

җир кишәрлеген карау һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү предметына бәя бирү өчен урынга бару кирәклеге турында карар кабул итә;

җир кишәрлеген карау һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү кирәк булган очракта, тикшерә һәм фотога төшереп терки, тикшерү актын әзерли;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле рәсмиләштерелгән документлар комплектын карый;

Регламентның 2.8.3 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

гражданин торак пункт, бакчачылык чикләрендә шәхси торак төзелеше, бакчачылык, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгать итсә, крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирү турында гражданның яисә крестьян

(фермер) хуҗалыгының гаризалары керсә, билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлеге бирү һәм аукционда катнашырга ниятләгән затлардан гаризалар җыю турында хәбәрнамәне бастыра һәм бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: карау акты, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, җир кишәрлеген бирү турында белдерү, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар комплекты.

Административ процедуралар бер эш көне дәвамында, җир кишәрлеген карау һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү предметына бәя бирү өчен урынга чыгу кирәк булган очракта –13 эш көне дәвамында башкарыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә урнаштырылганнан соң 30 көн эчендә аукционда катнашырга ниятләнгән затлардан гариза килгән очракта, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар проекты һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар проекты әзерли;

Регламентның 2.8.3 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын әзерли;

әзерләнгән карар проектларын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә килештерүгә җибәрә;

Административ процедуралар ике эш көне дәвамында башкарыла.

3.6.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карарлар проектларын, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын килештерү һәм имза кую (алга таба – карар проекты) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

Кисәтүләре булган әзерләнгән документ проектлары муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка эшләп бетерү өчен кире кайтарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар, территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар.

Административ процедуралар ике эш көне дәвамында башкарыла.

3.6.4. Техник мөмкинлек булганда, Регламентның 3.6.2-3.6.4 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь вакыты 17 эш көне тәшкил итә, киләчәктә җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан очракта - 49 эш көне.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.7.1. Административ процедураны үтәүне башлау өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затның муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ алуы тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Палата рәисенең урынбасары (алга таба-документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару системасына һәм (яисә) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасына теркәүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне кертүне тәэмин итә;

җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карарны һәм (яки) территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслау турында карарны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮтә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Техник мөмкинлек булганда, процедураларны үтәү, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Палатаның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка имза куйган көнне үтәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматны мәгълүмат системаларында урнаштыру, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре һәм аны алу ысуллары турында мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итү.

3.7.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.7.2.1. Мөрәҗәгать итүче КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен электрон документның басма чыганактагы нөсхәсе формасында бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча, аңа электрон документның кәгазь чыганактагы нөсхәсе белән бергә, алынмалы мәгълүмат туплагычка яздыру юлы белән электрон документның нөсхәсе бирелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүченең килү көнендә КФҮнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда башкарыла.

3.7.2.2. Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган, Палатаның вәкаләтле вазыйфаи затының

(Палатаның) көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган документның электрон үрнәге шәхси кабинетка автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Палатаның вәкаләтле вазыйфаи заты (Палата) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документка имза куйган көнне үтәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Республика порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ җибәрү (бирү).

3.8. Техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуныраслый торган юридик көчкә ия документлар.

Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гаризаны почта аша (шул исәптән электрон почта аша) яисә Республика порталы яки КФҮ аша бирә.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазифаи зат документларны карый һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләрне кертү максатыннан әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алып һәм шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән документны бирә яисә мөрәҗәгать итүче адресына почта аша (электрон почта аша) техник хаталы документның төп нөсхәсен Башкарма комитетка җибәргәндә документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хаталар ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту формалары

### 4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларының үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә ала: гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документларның проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүмат базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка белешмәләр файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм җирле үзидарә органы җитәкчесенә карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп тору өчен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Вакытларны, административ процедураларны бозу очраклары, аларның эзлеклелеге һәм аларны карап тоту сәбәпләре турында вазыйфаи затлар муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итәләр, шулай ук хокук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруны гамәлгә ашыручы бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

### 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты буенча планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм формалары

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы

тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча карала ала.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затларының муниципаль хезмәт күрсәтү барышында алар кабул итә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибенә һәм формаларына таләпләрне, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да характерлаучы нигезләмәләр

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аркылы тормышка ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның муниципаль хезмәткәренең, җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең кылган гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуны теркәү вакытын, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән таләпне бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән баш тарту нигезләре каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

6) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән вакытын бозуы. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән туктатып тору нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренчел баш тарткан вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөрес түгеллеге турында хәбәр ителмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү. Әгәр шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь чыганакта, электрон формада муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысы булган дәүләт хакимиятенең тиешле органына (алга таба - күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югары органга (ул булган очракта) бирелә яисә ул булмаганда, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкнең гамәлгә куючысына яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге оешма җитәкчеләренә тапшырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын,

Бердәм порталны яисә Республика порталын, судка кадәр шикаять бирүнең мәгълүмат системасын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында алынырга мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтын, Бердәм порталны яисә Республика порталын, судка кадәр шикаять бирүнең мәгълүмат системасын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында алынырга мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, Бердәм порталны яисә Республика порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, аларның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәрләренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең шикаять ителүче карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның яисә аларның хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә нигез булган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Кергән шикаять кергән көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең оештыручысына, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (ул булган очракта) кергән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә каралырга

тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең оештыручысының, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга карата шикаять белдергән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларыннан муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба муниципаль хезмәт алу максатларыннан мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланганда, шикаятьне карап тикшерү буенча вәкаләтләр бирелгән вазифаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

1а номерлы кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында

____________________________гаризасын карап, (ИНН____), _____ _____, _____номерлы Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр, күчемсез милек дәүләт кадастры белешмәләре, Россия Федерациясе Җир кодексының _____ статьялары нигезендә:

1. Территориянең кадастр планында __________________________________ территориаль зона чикләрендә урнашкан дәүләт милкендәге җирләрдән төзелгән _____ кв. м. мәйданлы_________________________җир категориясеннән булган җир кишәрлегенең урнашу схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән гомуми мәйданы _____ кв. м булган төзелә торган җир кишәрлегенә___________________________________ рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләргә.

3. Әлеге күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән төзелә торган_____ кв. м мәйданлы җир кишәрлегенә ____________________________адресы бирергә.

4. _____ кв. м. мәйданлы_________________________җир категориясеннән булган _____________________________адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген __________________________ ______________ яшәү урыны адресы:_____, паспорт сериясе _____№ _____ бирүне алдан килештерергә.

5. Әлеге күрсәтмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген бирү, аның барлыкка килүенә бәйле рәвештә, җир кишәрлегенең дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру шарты белән башкарылачак.

6. ___________________ сорала торган җир кишәрлегенең дәүләт кадастр исәбен алып бару турында гариза белән ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Башкарма комитетның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре идарәсенә бу күрсәтмәне дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә күрсәтмә кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә җибәрергә кирәк.

8. Башкарма комитетның Архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак төзелеше идарәсенә әлеге күрсәтмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегенең адресы турындагы мәгълүматларны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт адреслы реестрында урнаштыруны тәэмин итәргә.

9. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Имза ФИА

1б номерлы кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

(Килештерүне гамәлгә ашыручы орган бланкы)

Хәбәрнамә

______________________________________________________________________

( мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а.и., юридик затның исеме )

_________________ел, №__
__________________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле ____________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

нигезендә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә бәйле рәвештә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазифаи зат (ФИА) ______________________________________

(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазифаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИА)

_________________________________

(башкаручы элемтәләре)

2 нче кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

(Килештерүне гамәлгә ашыручы орган бланкы)

Хәбәрнамә

(Хезмәт күрсәтү өчен җаваплы муниципаль берәмлек исеме)

___________________________________________________________________________

(Физик затның Ф.И.А., юридик затның– мөрәҗәгать итүченең исеме)
____________ елның______________ _________ номерлы гаризасын карап тикшергәннән соң, түбәндәге сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында хәбәр итә:

(РФ Җир кодексының 39.15. статьясы. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү, 6 пункт)

«Әгәр вәкаләтле органга төзелүе әлеге гаризага кушымта итеп бирелгән җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза кергән көнгә, мондый орган каравына элегрәк тәкъдим ителгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы һәм бу схемаларда каралган җир кишәрлекләренең урнашу схемасы өлешчә яисә тулысынча туры килә торган җир кишәрлекләренең урнашу схемасы керә икән, вәкаләтле орган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында соңрак бирелгән гаризаны карау вакытын туктатып тору турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә».

Вазифаи зат (ФИА) ________________________________________

(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазифаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИА)
________________________________

(башкаручы элемтәләре)

3 нче кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

___________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)
кемнән________________________________________
(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

_____________________________________________
(юридик затлар өчен - исеме, урнашкан урыны, оештыру-хокук формасы, ЕГРЮЛ, ОГРНда дәүләт теркәве турында мәгълүматлар)
_____________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза

Сездән_______________________________________________ нигезендә,
(РФ ҖК 39.3 ст. 2 п., 39.5 ст., 39.6 ст. 2 п. яки 39.10 ст. 2 п. каралганнар арасыннан нигез күрсәтелә).
___________ муниципаль район (шәһәр округы), ______________________торак пункты, ________________ ур., ______й., ______________ адресы буенча урнашкан ___________ кв.м. мәйданлы, ________:___ кадастр номерлы, _____________________________________________________________________өчен
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)
_______________________________________нә җир кишәрлеген бирүне алдан
(гариза бирүче җирне сатып алырга тели торган хокук төре)
килештерүегезне сорыйм.
Өстәмә белешмәләр (түбәндәге шартлар булганда тутырыла):
_____________________________________________________________________
җир кишәрлеге дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген алу турында карар реквизитлары

_____________________________________________________________________
территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турындагы карар реквизитлары, әгәр җир участогы әлеге документта һәм (яки) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән булса;

Гаризага түбәндәге документлар беркетелә:

1) мөрәҗәгать итүченең торглар үткәрмичә җир кишәрлеген алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә вәкаләтле органга тапшырылырга тиешле документлардан тыш;

2) җир кишәрлегенең урнашу схемасы (*әгәр дә сорала торган җир участогын төзергә туры килә һәм мондый җир кишәрлеге төзелергә тиешле территорияне ызанлау проекты булмаса*);

3) урман кишәрлекләренең урнашу урыны, чикләре, мәйданы һәм башка сандагы һәм сыйфат характеристикасы турында проект документлары (*әгәр дә урман кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза бирелгән булса*);

4) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (*әгәр җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать итсә*);

5) чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларны (*әгәр мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булса*) рус теленә таныкланган тәрҗемә;

6) гражданнар төзегән коммерцияле булмаган оешма тарафыннан әзерләнгән аның әгъзалары исемлеге (*әгәр дә яшелчә бакчачылыгын яки бакчачылыкны алып бару өчен җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү яки әлеге оешмадан түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән булса*).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәгечә җибәрүегезне сорыйм:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә кәгазь чыганактагы электрон документ нөсхәсе формасында.

________________________ телефоны аша миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм.

______________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

4 нче кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

(Килештерүне гамәлгә ашыручы орган бланкы)

Хәбәрнамә

(Хезмәт күрсәтү өчен җаваплы муниципаль берәмлек исеме)

_______________________________________________________________________________

(Физик затның Ф.И.А., юридик затның– мөрәҗәгать итүченең исеме) _________
елның_____________ ____________ номерлы, җир кишәрлегенең гаризага кушып бирелгән урнашу схемасы нигезендә барлыкка китерергә тиеш булачак җир кишәрлеген алдан килештерү турында гаризасын карап тикшергәннән соң, түбәндәге сәбәпләр аркасында җир кишәрлеген урнаштыру схемасының башка вариантын раслауга язмача ризалык бирергә тәкъдим итә:
_____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________
__________________________________________
_____________________________________________________________________________________________
__________________________________________
(аңлатмалар)
Җир кишәрлегенең урнашу схемасының башка вариантын раслау өчен 5 календарь көн эчендә язмача ризалык бирергә кирәк.
(РФ Җир кодексының 39.15 статьясы. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү, 12 п.)

Кушымта: Вәкаләтле орган әзерләгән территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасы.

Вазифаи зат (ФИА) ________________________________________

(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазифаи заты имзасы)
М.У.

Башкаручы (ФИА)
________________________________
(башкаручы элемтәләре)

5 нче кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

(Килештерүне гамәлгә ашыручы орган бланкы)

Хәбәрнамә

_______________________________________________________________________
( мөрәҗәгать итүче физик затның ф. и. а.и., юридик затның исеме )

_________________ел,     №__
_____________________________________________________________________________ турындагы

гариза белән мөрәҗәгатенә бәйле ____________________________________________________________
__________________________________________________________________________________

нигезендә тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә бәйле рәвештә документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазифаи зат (ФИА)                    _______________________________________
(килештерүне гамәлгә ашыручы органның вазифаи заты имзасы)

Башкаручы (ФИА)
_______________________________
(башкаручы элемтәләре)

6 нчы кушымта
Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

«Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисенә
___________________________тан

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:_____________________________________________________________
_______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:________________________________________________
____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:____________________;
расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: ____________________________________________________________________.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мине вәкилләгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

_______________ __________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.)